Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе______ Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча директор урынбасары
______Исмәгыйлева Г.Т.
“ 28 ” август 2017ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
______Сабирҗанова Г.Т.
Приказ №
« 28» август 2017 ел

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**“ Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”**
**муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

# Әдәби укудан эш программасы

**3 нче сыйныф**

**Нурлыгаянова Гүзәл Гөлүс кызы, башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы утырышы беркетмәсе № 1
28 нче август, 2017 ел

**2017 – 2018 нче уку елы**

## Аңлатма язуы

Эш программасы “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль); “2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004 ел, 11 октябрь); Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь); Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; ”Әдәби уку” авторлык программасына. Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2011; МБГББУ «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, “Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы” турындагы нигезләмәсенә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Программа елга 68 сәгатькә (атнага 2 сәгать) каралган.**

Программа үтәлү өчен түбәндәге **укыту-методик әсбаплар** кулланыла:

1.Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен дәреслек. 3 кисәктә.1 нче кисәк/(Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).-Казан: “ Мәгариф-Вакыт” нәшр.,2013.

2.Әдәби уку: татар телендә башл. Гомуми белем бирү мәкт.3нче с-фы өчен дәреслек.3 кисәктә.2нче кисәк/(Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).-Казан: “ Мәгариф-Вакыт нәшр.,2013.

3.Әдәби уку: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәкт.2 нче с-фы өчен дәреслек.3 кисәктә. 3 кисәк: дәреслек-хрестоматия/(Г.М.Сафиуллина һ.б. рәссамы Ф. Ризаева).-Казан:” Мәгариф-Вакыт нәшр.,2013.

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге **мәсьәләләрне** хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле **гомумдидактик бурычлар**: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга тиеш.
2. Бала яшенә туры килә торган **теоретик бурычлар**:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турыщдагы автор әкиятләренең еш кына халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларак әйтелми);* халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

3. **Әхлакый бурычлар**: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү – байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;

4. **Эстетик бурычлар**: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;

5. **Сөйләм телен үстерү бурычлары** -текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка - бу «синең» әсәрне аңлау;идеяң икәнен җайлап төшендерү.

Дәреслек һәм дәреслек-хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре структуралары һәм идея эчтәлекләре буенча бер – берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең «Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз», «Чагыштырулар серенә төшенәбез», «Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз», « Ярату турында», “ Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз”, Көлке серләре”, “Герой ничек туа?”, “Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз” бүлекләренә дәреслек – хрестоматиянең һәм эш дәфтәреннең шул ук бүлекләре туры килә.

Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре дә бер үк максатларны тормышка ашыра.

**Искәрмә.** «Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең ,,Укыту курслары һәм предметларыннан эш программалары төзелеше, аларны эшләү тәртибе турында” гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августта чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 3 нче а сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыруның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашу нәтиҗәләре:**

- үз илең, халкың һәм тарихың белән горурлану хисләре формалаштырырга, һөнәрләр дөньясы белән танышырга, җәмәгать урыннарында, мәктәптә үз-үзеңне тотуның әхлакый кагыйдәләрен үзләштерергә;
- уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштырырга;
- әдәби мәдәният нигезендә матурлыкны күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштырырга.
- белем бирү учреждениесенә унай караш, әдәби уку фәнен өйрәнүнең кирәклеген аңларга;
- уку эшчәнлегенең уңышлылыгы (унышсызлылыгы) сәбәпләрен аңларга;
- аралашканда иптәшеңнең мотивларына һәм хисләренә ориентлашырга, үз-үзеңне тотышыңда мораль нормаларга һәм этик таләпләргә тотрыклы иярергә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре формалашу нәтиҗәләре:**

- максатка ирешүдә үҗәтлек, авырлыкны җиңүгә әзер булу, авырлыкларны чишү ысулларын эзләүгә ихтыяҗ формалаштырга;
- ирешеләчәк нәтиҗәне алдан күрергә;
- проблеманы чишүдә берничә вариант табарга,аларны кулланып карарга;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләргә, уңышлылыгына бәя бирергә;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылырга;
- укытучы белән хезмәттәшлектә итәргә;
- уку хезмәттәшлегендә танып белү инициативасы күрсәтергә;
- укытучы тарафыннан билгеләнгән эш-гамәлне мөстәкыйль рәвештә яңа уку материалында исәпкә алырга;
- эш-гамәлләрнең дөрес үтәлешен мөстәкыйль рәвештә бәяләргә һәм тиешле төзәтмәләр кертергә.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре формалашу нәтиҗәләре:**

- эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп барырга;
- охшашлык һәм аермалыкларны аерырга, чагыштырырга;
- аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салырга;
- нәтиҗә чыгарырга;
- охшашлыклар урнаштырырга;
- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтергә;
- проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табарга.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалашу нәтиҗәләре:**

- укытучы, туганнар, әти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру – катнашучыларның максатларын, вазифаларын үзара аралашу ысулларын билгеләргә;
- сораулар формалаштырырга, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белергә;
- проблеманы ачарга, аны тормышка ашырырга, үзара килешүгә ирешергә;

- эшлекле партнерлы аралашырга, төркемдә үзара ярдәм итешергә;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык , аңлаешлы итеп әйтергә, аны якларга.

**Предметны өйрәнү нәтиҗәләре:**

- әсәрләрне сәнгатьле  һәм хатасыз уку;
- әсәрдәге  өзекләрне сайлап ала, рәсемгә төшерә  белү;
- Рәсемнәр  һәм  әсәрләр арасындагы бердәмлекне таба белү;
- әдәби  әсәр белән эшли белү;
- укылган  әсәрне хикәяли белү;
- әсәрләрне сәхнәләштерә  белү;
- текстны рольләргә  бүлеп укый белү;
- әсәр геройларына кыскача характеристика бирә белү;
- язучыларның  кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарын белү.

## Укыту - тематик планлаштыру

| № | Бүлек һәм темаларның исеме | Барлык сәгатьләр |
|---|---|---|
| 1 | Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз | 15 |
| 2 | Чагыштырулар серенә төшенәбез | 6 |
| 3 | Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз | 7 |
| 4 | Ярату турында | 9 |
| 5 | Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз | 7 |
| 6 | Көлке серләрен эзлибез | 4 |
| 7 | Герой ничек туа? | 9 |
| 8 | Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз | 11 |
| | **Барысы** | **68** |

## Укыту предметының тематик эчтәлеге

**1. Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз (15 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Табигатьнең гүзәллеген әдәби һәм сәнгать әсәрләре аша аңлату. Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтеп барырга, күргәннәрең белән уртаклашырга өйрәтү. Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьләрдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).

Б. Рәхмәт "Иң күңелле чак", Р. Хисмәтуллин «Июль аланы», Р. Вәлиева "Җәй һәм бала", М. Галиев «Җиләктән кайтканда», М. Мирза "Күздә бермәл", "Күз", "Болыт", Б. Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М. Гафури "Болын", Н. Дәүли «Бала болыт», . Р. Корбан "Күз нигә моңая", Р. Вәлиева "Яңгыр, яу!", "Китмә әле, бераз тор", Йолдыз "Салават күпере", М. Әлимбаев "Салават күпере", Л. Лерон «Яңгырның ял көне», М. Җәлил  "Яңгыр", Р. Мингалим «Август каеннары», Ш. Маннур "Көзге урманда", З. Туфайлова «Яфрак ява», Х. Әюпов «Әбиләр чуагы», К. Тәхау "Көзге урман", Р. Әхмәтҗан "Соңгы яфрак", М. Мазунов «Карап торам», Г. Хәсәнов «Кыр казы», Г. Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе», Н. Гыйматдинова «Казлар», Г. Остер «Серне ачты», В. Хәйруллина "Тәрбияче попугай", Н. Сладков "Күзалдавычлар", Р. Әхмәт "Сыкы", Н. Сладков "Кем остарак", Р. Корбан "Мәктәпкә озату бәйрәме", Г. Паушкин "Кыш", Г. Рәхим "Безнең тауда", Н. Әхмәдиев "Чишмәгә суга барам", К. Кәримов "Кышкы мәтрүшкәләр", Н. Гыйматдинова Сарбай".

**Эш формалары**: практик-уен, экскурсия, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Кеше һәм табигать бергәлеген, дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзалларга,әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инанырга. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитетларны аерырга, автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлыкны,чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белергә, аңлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерергә(темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү)

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу.

**2. Чагыштырулар серенә төшенәбез (6 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау.

Әфган халык әкияте: " Иң яхшы дару", "Табышны ничек бүләргә?", "Кабартма"; Уйгур халык әкияте: "Тылсымлы китмән"; Инглиз халык әкияте: "Көрән төстәге пингвин баласы"; Монгол халык әкияте: "Әтәч таңда нигә кычкыра?"; Манси халык әкияте: "Куянның колагы

нигә озын?”; Кабарда халык әкияте: “Җәнлекләр патшасы”; Венгр халык әкияте: “Комсызлык бәласы”; Африка негрлары әкияте: “Сырны ничек бүлгәннәр?”; Эстон халык әкияте: “Куянның ирене нигә ярык?”; Эвенк халык әкияте: “Әтәч нигә кычкыра?”; Казакъ халык әкияте: “Юмарт дөя”; Нугай халык әкияте: “Карт һәм су анасы”; Норвегия халык әкияте: “Кабартма”; Алман халык әкияте: “Сандугач белән Аю”; Каракалпак халык әкияте: “Җәй белән Кыш нигә көрешми?”; Латыш халык әкияте: “Шайтанга ничә яшь?”; Литва халык әкияте: “Итагатьле мәче”, Л. Лерон “Әкияти башламнар”, Йолдыз “Охшашлык”, Э. Шәрифуллина “Әкият кайда?”

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Дәреслекнең төзелешен белергә,әкиятләрнең автор һәм халык әкиятләренә бүленешен аерырга,эчтәлек битендә ориентлаша алырга, халык һәм автор әкиятләрен аерырга, иллюстрацияләр аша  әкиятләрне танырга,әкиятләрне мәгънәви кисәкләргә бүлә белергә,кыен хәлләргә калганда авырлыкларны җиңә белергә, әкиятләрнең үзенчәлекләрен мөстәкыйль рәвештә күрә белергә, укыган әкиятләр арасыннан тылсымлыларын аера белергә, җәнлекләр турындагы татар халык әкиятләрен башка халык әкиятләре белән чагыштырып үзенчәлекле якларын таба белергә

**Милли төбәк компоненты:** Төрле халык авыз иҗаты белән танышу.

**3. Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз. (7 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы – тыңлаучыга табигый көчләрнең серен , әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының  характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү. Уйдырмаларның максаты – тыңлаучыларны дөньяда булмаган,уйлап чыгарылган хәлләр белән шаккатыру.

Л. Лерон “Хыял”, Йолдыз “Антенналы бәрәңге”, Л. Лерон “Хыялый Акбай”, Ә. Габиди “Тере антенналар”, Л. Лерон “Мәче малае Шукбай”, “Шукбай балык тота”, “Хат”,  Ф. Мөслимова “Хыялый”, З. Гомәрова “Хыялларым”, Б. Рәхмәт “Ничек өйрәнергә”, Р. Фәйзуллин “Тугайда”, А. Әхмәтгалиева “Болытта җиләк үсә”, Ф. Садриев “ Юкка көттеләр”, А. Гыйләҗев “Суык”, А. Аланазаров “Дустымны эзлим2, В. Хәйруллин “Кем булам”, Йолдыз “Этем югалды бүген”, Р. Гыйзәтуллин “Батырлык”, Г. Рәхим “Иске самавыр торбасы”.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Хыял һәм фантазия турында белгәннәрне искә төшерү, яңа мәгълүматлар белән баету. Күзәтүчәнлек, уйлап табучанлык һәм яңалыкка омтылыш булдыру. Әсәрдәге төп фикерне ачыклау. “Хыял һәм чынбарлык” турында фикерләү, күзалларга өйрәнү.

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу.

**4. Ярату турында. (9 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

“Ярату”  төшенчәсенең мәгънәсен әдәби әсәрләрдәге вакыйга һәм образлар язмышы аша аңлату: гаиләне хөрмәтләү, гаилә әгъзаларына, туган җиргә карата ярату хисләре, кече туганнарыбызга мәхәббәт. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану.

Р. Вәлиев “Барысын да яратам”, Ш. Маннур “ Яратам”, Р. Вәлиева “Чыпчык”, М. Хөсәен “Китап”, С. Урайский “Туган ил”, А. Гыймадиев “Шәмси мажаралары”, Н. Кәримова “Авылым җыры”, В. Нуриев “Кем катырак суга?”, Р. Вәлиева “Яңгыр белән Кояш”, Г. Сабитов “Тәүге шатлык”, Ә. Баянов “Тургай”, Н. Гыйматдинова “Болын патшасы”, А. Әхмәтгалиева “Безнең чишмә”, Г. Бәширов “Беренче

кар”, Н. Сладков “Кышкы җәй”, М. Мазунов “Яңа карлар ява”, И. Солтан “Кар ник шыгырдый?”, И. Солтан “Кар ник ява?”, Р. Мәннан “Кыш килә”, Ф. Зыятдинов “Муллык билгесе”, М. Мирза “Кышның китәсе килми”, Р. Миңнуллин “Кар бәйрәме”, С. Урайский “Кыш шатлыгы”, Р. Вәлиева “Каникул вакытында”.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

“Ярату” төшенчәсенең мәгънәсен әдәби әсәрләрдәге вакыйга һәм образлар язмышы аша аңлау. Гаиләне хөрмәтләү, гаилә әгъзаларына, туган җиргә карата ярату хисләре, кече туганнарыбызга мәхәббәт булдыру.

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу.

**5. Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз (7 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:** Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү. Төрле халык мәкальләре . Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып тану. Мәсәл һәм әкиятне чагыштыру. Мәсәлләрнең хайваннар турындагы әкиятләрдән килеп чыгуы. Мәсәлләрнең төп асылы, эчтәлеге. Мәсәл моралендә мәкальләр куллану. Мәсәлләрнең тәрбияви роле.

Эзоп “Давыл белән Кояш”, Г. Тукай “Җил илә Кояш”, Н. Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”, татар халык әкияте “Ябалак белән чыпчык”, Ф. Яруллин “Мактану бәласе”, К. Насыйри “Төлке белән Әтәч”, М. Гафури “Мәймүн белән күзлекләр”, “Чикерткә белән кырмыска”, Г. Тукай “Көзге белән маймыл2, Г. Шамуков Көзге белән Маймыл”, Т. Яхин “Карга белән Төлке”, Ф. Яхин “Сыр бәласе”, Г. Шамуков “Карга белән Төлке”, М. Гафури “Ике белән бака”, В. Радлов “Карганың бәласе”, Л. Толстой “Зирәк Чәүкә”, С. Шакир “Таш белән Кырмыска”, Ә. Исхак “Карт Имән белән яшь егет”, М. Гафури “Ике чебен”, Г. Тукай “Яшь агач”, Г. Тукай “Төлке белән йөзем җимеше”, Ә. Исхак “Төлке белән виноград”, Г. Вәлиева “Заман әкияте”, Г. Тукай “Аккош, Чуртан һәм Кыскыч”, И. Крылов “Аккош, Чуртан һәм Кысла”, М. Гафури “Кәҗә белән Төлке”.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше белән таныш булу. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж.Лафонтен, И.Крылов, татар мәсәлчеләре К.Насыйри, Г.Тукай,М.Гафури, Г.Шамуков, Ә.Исхак һәм башка язучыларны белү һәм әсәрләрен өйрәнү.

**Милли төбәк компоненты:** Танылган мәсәлчеләр һәм татар мәсәлчеләре иҗаты белән танышу.

**6. Көлке серләрен эзлибез (4 сәгать)**

**Бүлекнең эчтәлеге:** Шигырьләрдә автор фикерен аерып алу. Шагыйрьнең кимчелекләрдән көлүе. Көлкеле әсәрләрдә көлке китереп чыгарган сәбәпләрне табу.

Ш. Галиев “Иншаның файдасы”, “Сүзләре һәм үзләре”, В. Нуриев “Инша”, Л. Лерон “Иртән уянасың килмәсә”, Сүз тыңлыйсың килмәсә”, “Инша”, Р. Вәлиева “Көчле укучы”, “Сыер эзләгәндә”, К. Тәңрекулиев “Эшчән” Гельды”, И. Юзеев “Хатасыз ничек язарга?”, Р. Миңнуллин “Хаталар өстендә эшләү”, Г. Морат “Үскәч кем булырга”, “Тиргиләр”, Р. Низамова “Табигать күренеше”, Р. Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга?”, Йолдыз “Ике җаваплы табышмак”, Н. Кәримова “Кое чыпчыгы”, З. Туфайлова “Трай”, А. Алиш “Утлы йомрка”, Р. Вәлиев “Минеке”.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:** Шигырьләрдә автор фикерен аерып ала белү. Шагыйрьнең кимчелекләрдән көлүен, көлкеле әсәрләрдә көлке китереп чыгарган сәбәпләрне табу. Язучы һәм шагыйрьләрнең көлкеле әсәрләрен белү.

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу.

**7. Герой ничек туа? (9 сәгать)**

**Бүлекнең эчтәлеге:** Автор әкиятләрендә, нәкъ халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе, аерым сүзләрнең ритмик кабатланып килүе. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Язның тәүге үзенчәлекләрен әсәрләрдән табу.

Ф. Яруллин "Тылсымлы ачкыч", Р. Мингалим "Уйларга кирәк", Р. Харис "Берсе калсын иде", Р. Вәлиева "Кышкы ямь", Йолдыз "Белмәгәнен белми", М. Мирза "Язның тәүге көннәре", Г. Хәсәнов "Корташар", "Гөблә", "Май", Г. Гыйлман "Көзге урман", Ф. Садриев "Белемле әби", Х. Халиков "Витаминлы аш", Н. Гыйматдинова "Дару".

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, экскурсия, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Автор әкиятләрен анализлый белү. Автор теленең кабатланмас матурлыгын тою. Язның тәүге үзенчәлекләрен әсәрләрдән таба белү.

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу.

**8. Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз (11 сәгать)**

Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны табу. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы ( тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

Хикәя геройлары , аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы.Авторның үз героена мөнәсәбәте.Геройларга чагыштырма характеристика.Герой яшәгән тирәлек,пейзаж.

Р. Фәйзуллин "Онытма син!", М. Мирза "Идел-йорт", "Без бабайсыз үстек", Р. Рәкыйпов "Мин яратам сине, Татарстан!", Л. Шагыйрьҗан "Сөембикә манарасы", В. Нуриев "Хуҗалар тавы", Х. Туфан "Казан", З. Гомәрова "Батырлар хакында", Р. Харис "Сугыш турында сөйләшә картлар", "Игенче җыры", Г. Гыйлман "Нәсел агачы", "Дәү әтинең әтисе", "Универсиада", Ф. Кәрим "Ант", Ватаным өчен", М. Җәлил "Кичер, илем!", Х. Халиков "Рәхмәт сезгә, ветераннар!", В. Нуруллин "Бүреләр, үгез һәм без", С. Рәхмәтуллин "Сандыктагы хәзинә", Р. Мәннан "Без музейга барабыз", Г. Ахунов "Канатлар кая илтә?", Г. Моратов "Корыч шулай чыныкты", И. Юзеев "Матурлыкны гына алып кит", Г. Бәширов "Безнең Татарстан", Р. Фәйзуллин "Нефть", "Безнең КамАЗ", Йолдыз "Спортчы Шүрәле", Р. Миңнуллин "Кунакка килегез".

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, экскурсия, төркемдә һәм парларда

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы ( тавышны күтәрү, түбәнәйтү). Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышын, авторның үз героена мөнәсәбәтен, геройларга чагыштырма характеристика бирә белү.

**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты белән танышу.

## Календарь-тематик планлаштыру

| | Теманың эчтәлеге | Үткәрү вакыты | | Укучылар эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|
| | | План | Факт | |
| 1. | Иң күңелле чак. Бари Рәхмәт "Иң күңелле чак". И.Грабарь "Сентябрь кары" | 04.09. | | Аңлап, дөрес, йөгерек уку |
| 2. | Җәйне сагыну. М. Галиев "Җиләктән кайтканда", Г.Эйдинов "Мастерской тәрәзәсе | 07.09. | | Аңлап, дөрес, йөгерек уку. М.Галиевның шигыре белән таныштыру. Табигатькә мәхәббәт тәрбияләү. |
| 3. | Күк йөзендә болыт-рәсемнәр. Б.Рәхимов."Шук болытлар, батыр җил, якты кояш", Р. Корбан "Көз нигә моңая?" | 11.09. | | Шигырь белән таныштыру. Укучыларны аңлап йөгерек укырга өйрәтү. Язучының иҗаты. |
| 4. | Яңгырның ял көне. Л. Лерон "Яңгырның ял көне", Ф. Васильев "Яңгыр алдыннан". | 14.09. | | Әсәрнең төп фикерен билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү, сәгатьле уку. |
| 5. | Җир өстенә яфрак ява. Р.Мингалим "Август каеннары"З. Туфайлова "Яфрак ява", .Мәннур "Көзге урманда". | 18.09. | . | Укылганның эчтәлеген тулысынча, кыскача, сайлап һәм иҗади сөйләү.Тексттан табигать һәм көнкүреш тасвирламаларын аерып күрсәтү |
| 6. | Алтын көз. Ф.Хөсни "Яфрак коелганда", И.Остроухов "Алтын көз" | 21.09. | | Сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру. Әсәргә картиналы план төзергә өйрәтү. |
| 7. | Кыр казлары китә җылы якка. М.Мазунов "Карап торам", Г.Хәсәнов "Кыр казы" | 25.09. | . | Укучыларда сәнгатьле уку күнекмәләрен формалаштыру, сөйләмнәрен үстерү. |
| 8 | Йорт казлары - гаҗәп кызык кошлар. Г.Бәширов "Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе" | 28.09. | | Әсәрдән алынган фактлар белән үз карашларын исбатлый белергә өйрәтү. Кошларны белү |
| 9 | Йорт казлары - гаҗәп кызык кошлар. Г.Бәширов "Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе" | 02.10. | | Мәкальләрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү, сәнгатьле уку күнекмә-ләрен формалаштыру, сөйләмнәрен үстерү. Икмәкнең кадерен бе-лергә өйрәтү. Игенче хезмәтенә хөрмәтләү |
| 10. | Тәрбияче попугай. Г.Остер "Серне ачты" | 05.10. | | Укучыларның фикерләү күнекмәләрен үстерү. |
| 11. | Әнис Шакировның куен дәфтәре. Н.Сладков "Күзалдавычлар", Р.Әхмәт "Сыкы" | 09.10. | | Әсәрдән алынган фа-ктлар белән үз карашларын исбатлый белер-гә өйрәтү. Укучыларның фикерләү күнекмәләрен үстерү. Табигать-кә мәхәббәт тәрбияләү. |
| 12. | Әнис Шакировның куен дәфтәре. .Сладков."Кем остарак?", Р.Корбан "Мәктәпкә озату бәйрәме" | 12.10. | | Сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру. Әсәргә картиналы план төзергә өйрәтү. |
| 13. | "Серле ачкыч" клубы утырышы. Г.Паушкин | 16.10. | | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Кыш”, Г.Рәхим “Безнең тауда” | | | әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү |
| 14. | Серле чишмә, моңлы чишмә. Н.Әхмәдиев "Чишмәгә суга барам" | 19.10. | | Әсәрнең мәгънәле кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерен бил-геләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп би-рергә өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү. |
| 15. | Сарбайның батырлыгы. Н.Гыйматдинова “Сарбай” | 23.10. | | Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү.Туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү |
| 16. | Эш кешене тәрбияли, ялкаулык боза. Әфган халык әкияте "Иң яхшы дару" уйгур халык әкияте "Тылсымлы китмән" | 26.10. | | Авторның төп уен тирән, ачык итеп аңлау-ларына ирешү һәм әсәргә карата үз караш-ларын формалаштыру. Укучыларның матур әдәбият белән кызык-сынуларын арттыру |
| 17. | Һәр җәнлекнең үз төсе. Инглиз халык әкияте: “Кәрән төстәге пингвин баласы” | 06.11. | | Укучыларда  текстны аңлап укырга, укылган өлешнең эчтәлеген сөйләргә өйрәтү. |
| 18. | Эш үткәч, үкенүдән файда юк. “Әтәч таңда ник кычкыра?” (Монгол халык әкияте) | 09.11. | | Әсәрнең тәрбияви әһәмиятен билгели белергә өйрәтү |
| 19. | И куян, куян... . "Куянның колагы нигә озын". Манси халык әкияте | 13.11. | | Укылган әсәр буенча әңгәмәдә катнашу, сорауны ишетү, аңлау һәм темага бәйле рәвештә җавап |
| 20. | Җәнлекләр арасында да патшалар була. “Җәнлекләр патшасы” (кабардин халык әкияте” | 16.11. | | Чыгыш ясый, үзенең билгеләмә һәм бәяләрен дәлилли, исбатлый |
| 21. | Комсызлык китергән бәла. Венгр халык әкияте "Комсызлык бәласе", Африка негрлары әкияте "Сырны ничек бүлгәннәр" | 20.11. | | Укылган әсәр буенча әңгәмәдә катнашу, сорауны ишетү, аңлау һәм темага бәйле рәвештә җавап |
| 22. | Хыял һәм фантазия арасындагы аерма  Л.Лерон “Хыял”, Йолдыз “Антенналы бәрәңге.” | 23.11. | | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. Телдән текст төзи белү |
| 23. | “Хыял һәм чынбарлык” турында төшенчә. Л.Лерон “Мәче малае Шукбай.” | 27.11. | | Укылган әсәргә тулы, кыска һәм рәсемле план төзү. Әсәрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү.Үзеңә ошаган өлешне табып укый белү |
| 24. | Мәчеләр дә кешеләрчә яши. Л. Лерон "Шукбай балык тота", "Хат" | 30.11 | | Укылган әсәргә тулы, кыска һәм рәсемле план төзү. Әсәрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү.Текстны аңлап уку |
| 25. | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы | 04.12. | | Укучыларны аңлап һәм сәнгатьле итеп укырга сөйләм культурасына өйрәтү. Балаларның сөйләмен баету. |
| 26. | Нәниләрнең хыялы.  А. Гыйләҗев "Суык" | 07.12. | | Сәнгатьле һәм йөгерек укуга ирешү.Укучыларда миһербанлык кебек уңай сыйфатлар, яхшы гадәтләр, түземлелек сыйфатлары тәрбияләү |
| 27. | Дүрт аяклы дустым. А. Алланазаров "Дустымны эзлим" | 11.12. | | Фикерне дөрес һәм төгәл итеп белдерү өчен бәйләнешле сөй-ләм күнекмәләрен үстерү. |
| 28. | Батырлыкка җирдә урын бар. Р.Гыйззәтуллин | 14.12. | | Укучыларны аңлап һәм сәнгатьле итеп укырга сөйләм культурасына |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | "Батырлык" | | | өйрәтү. Балаларның сөйләмен баету. Логик, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү. |
| 29. | Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү.Р.Вәлиев “Барысын да яратам.” Ш.Маннур “Яратам”, Р.Вәлиев “Чыпчык.” | 18.12. | | Логик, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү.<br>Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 30. | Авыл хикмәтләре. А.Гыймадиев "Шәмси маҗараралары" | 21.12. | | Әсәрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү.Чын кеше булып яшәү-гә өмет, ышаныч тәрби-яләү. Әсәрнең тәрбияви әһәмиятен билгеләү. |
| 31. | Җәйге кояш астында. В.Нуриев "Кем катырак суга". Р.Вәлиева "Яңгыр белән Кояш" | 08.01. | | Укылган әсәргә тулы, кыска һәм рәсемле план төзүне камилләштерү. |
| 32. | Шатлык - тәнгә сихәт. Г.Сабитов "Тәүге шатлык" | 11.01. | | Укылган әсәргә тулы, кыска һәм рәсемле план төзүне камилләш-терү.Балаларның сөйләмен баету |
| 33. | Болын патшасы. Н. Гыйматдинова “Болын патшасы”. Ф. Халиков “Гаилә портреты” | 15.01. | | Фикерне дөрес һәм төгәл итеп белдерү өчен бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү.Укучыларның фикерләү сәләтен һәм иҗади активлыгын арттыру. |
| 34. | Чишмә буенда. А.Әхмәтгалиева “Безнең чишмә”, Ф.Әминов “Су буе” | 18.01. | . | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 35. | Туган як кышы. Г.Бәширов "Беренче кар" | 22.01. | . | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 36. | Кар – ул муллык билгесе. М.Мазунов “Яңа карлар ява”, И. Солтан “Кар ник шыгырдый?” | 25.01. | | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләре формалаштыру. |
| 37. | Кыш шатлыгы. Р. Миңнуллин “Кар бәйрәме”. Р. Вәлиева “Каникул вакытында” | 29.01. | | Хәзерге татар әдәбияты әсәрләре. Ишеткәннәргә карата үз фикереңне белдерү |
| 38. | Мәсәл серләренә төшенәбез. Эзоп “Давыл белән Кояш”. Г.Тукай “Җил илә Кояш” | 01.02. | | Мәсәл персонажлары-ның үз-үзләрен тотышын кешеләрнең уй һәм хәрәкәтләре белән чагыштыра белү. |
| 39. | Тапкырлык үлемнән коткара. Н.Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”. Г Тукай “Көзге белән Маймыл” | 05.02. | | Мәсәлләрнең хикәяләү һәм мораль өлешләрен таба белү |
| 40. | Юк урында мактау – зарарлы эш. Т.Яхин “Карга белән Төлке”. Г.Шамуков “Карга белән Төлке” | 08.02. | | Эчтәлекне логик эзлеклелектә һәм төгәл сөйләү. Мәсәлләр һәм әкият арасындагы бәйләнешне таба белү |
| 41. | Көч җитмәслек нәрсәне акыл белән җиңеп була. В.Радлов “Карганың хәйләсе”. Л.Толстой “Зирәк Чәүкә” | 12.02. | | Акыл көченең барысыннан да көчлерәк икәненә төшендерү |
| 42. | Һәр максатка чара бар. Ә. Исхак “Карт имән белән яшь егет”. М.Гафури “Ике чебен” | 15.02 | | Хәзерге татар әдәбияты әсәрләре белән танышу. Ишеткәннәргә карата үз фикереңне белдерү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 43. | Эшең барып чыкмаса гаепне үзеңнән эзлә. Г.Тукай “Төлке һәм йөзем җимеше”. Ә. Исхак “Төлке һәм виноград” | 19.02. | | Әсәрне кычкырып яки яттан укыганда аның эчтәлеген, характерын төрле сурәтләү чаралары аша бирү. |
| 44. | Бердәмлектә – көч. Г.Тукай “Аккош, Чуртан һәм Кысла”. И.Крылов “Аккош, Чуртан һәм Кысла” | 22.02 | | Эчтәлек буенча фикер алышуда катнашу, текст ахырындагы биремнәрне төгәл үтәү |
| 45. | Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп. Ш.Галиев "Иншаның файдасы", "Сүзләре һәм үзләре" | 26.02. | | Ш.Галиев "Иншаның файдасы", "Сүзләре һәм үзләре" танышу, әсәрләрне сәнгатьле укырга өйрәнү |
| 46. | Бүләк зур булмас, укыган кеше хур булмас. И.Юзеев “Хатасыз ничек язарга”. Р.Миңнуллин “Хаталар өстендә эшләү” | 01.03 | | Хәзерге татар әдәбияты әсәрләре. Ишеткәннәргә карата үз фикереңне белдерү |
| 47. | Акылның кадере - әдәп белән, куәтнең кадере – сәләт белән. Р.Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга”. Йолдыз “Ике җаваплы табышмак” | 05.03. | | Әсәрне кычкырып яки яттан укыганда аның эчтәлеген, характерын төрле сурәтләү чаралары аша бирү. |
| 48. | Көнең бушка үтмәсен. Г.Морат “Тиргиләр”. З.Туфайлова “Трай” | 08.03. | | Дәрестә нинди яңа белемнәр алуыгыз турында күршегез белән фикерләрегезне уртаклашу |
| 49. | Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар. Ф.Яруллин “Тылсымлы ачкыч”. Р.Мингалим “Уйларга кирәк” | 12.03. | | Укылган яисә тыңланган әсәрнең эчтәлеге. Дөрес һәм йөгерек уку. Персонаж термины белән танышу |
| 50. | Ф.Яруллин “Тылсымлы ачкыч”. | 15.03. | | Укылган яисә тыңланган әсәрнең эчтәлеге. Дөрес һәм йөгерек уку. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү |
| 51. | Белер өчен дөресен, бик күп укырга кирәк. Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте. Р.Вәлиева “Кышкы ямь” | 19.03. | | Әсәрне кычкырып яки яттан укыганда аның эчтәлеген, характерын төрле сурәтләү чаралары аша бирү. |
| 52. | Гыйлем ачкычы – китап. Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте. Йолдыз “Белмәгәнен белми” | 22.03. | | Эчтәлек буенча фикер алышуда катнашу, текст ахырындагы биремнәрне төгәл үтәү |
| 53. | Шыбырдашып тама тамчылар. М.Мирза “Язның тәүге көннәре”. Г. Хәсәнов “Корташар” | 02.04. | | Эчтәлек буенча фикер алышуда катнашу, текст ахырындагы биремнәрне төгәл үтәү. Әсәрләрдә юмор хисе бирелеше, кызыклы урыннарны аеру. |
| 54. | Беренче күкрәү. Г.Хәсәнов “Май”. Ә.Рәшит “Яшенле яңгыр” | 05.04. | | Мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп геройлары-на характеристика бирү. Белем алуга, сәла-мәт яшәешкә омтылыш уяту, үзара һәм башка кешеләр белән иркен аралаша белү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 55. | Табигать – иң серле китап. Г.Хәсәнов “Май” | 09.04. | | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 56. | Шифалы яңгырлар. Г.Хәсәнов “Май”. Х.Халиков “Витаминлы аш” | 12.04. | | Дәрестә нинди яңа белемнәр алуыгыз турында күршегез белән фикерләрегезне уртаклашу |
| 57. | Канатлы дуслар. Г.Хәсәнов “Май”. Н.Гыйматдинова “Дару” | 16.04. | | Әсәрләрдә юмор хисе бирелеше, кызыклы урыннарны аеру. Әдәбиятта фантазия |
| 58. | Үткәнеңне онытма син! Р.Фәйзуллин “Онытма син!”. Р.Рәкыйпов “Мин яратам сине, Татарстан!” | 19.04. | | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 59. | Бик борынгы манара. Л.Шагыйрьҗан “Сөембикә манарасы”. В.Нуриев “Хуҗалар тавы” | 23.04. | | Төрле жанрдагы әсәрләрне ишетеп аңлау, укылган әсәрләрнең эчтәлеген сөйли белү. Сәнгатьле уку күнегүләре |
| 60. | Сабан туй – халык бәйрәме. М.Мирза “ Без бабайсыз үстек” “Музей йортына сәяхәт” | 26.04. | | Өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау. |
| 61. | Нәсел агачы. Г.Гыйльман “Нәсел агачы”. В.Хәйруллина “Хозурлык һәм горурлык” | 30.04. | | Төрле жанрдагы әсәрләрне ишетеп аңлау, укылган әсәрләрнең эчтәлеген сөйли белү. Сәнгатьле уку күнегүләре |
| 62. | Алар Ватан өчен көрәште. Ф.Кәрим “Ант”, “Ватаным өчен” | 03.05. | | Укучыларда үзлектән белем алу күнекмәләре булдыру; әдәби әсәрләр укуга кызыксыну тәрбияләү. |
| 63. | Рәхмәт сезгә, ветераннар! М.Җәлил “Кичер, илем!”. Х.Халиков “Рәхмәт сезгә, ветераннар” | 07.05. | | Укучыларның матур әдәбият белән кызык-сынуларын арттыру. Сугыш ветераннары-ның бүгенге тыныч тормыш өчен кан коюларын аңлау |
| 64. | Сугыш чоры балалары. В.Нуруллин “Бүреләр, үгез һәм без”. “Музей йортына сәяхәт” | 10.05. | | Әдәби әсәрләр аша сугыш чоры балаларының фаҗигале язмышын аңлау |
| 65. | Канатлар кая илтә? Г.Ахунов “Канатлар кая илтә?” Мәкальләр. “Музей йортына сәяхәт” | 14.05. | | Төрле жанрдагы әсәрләрне ишетеп аңлау, укылган әсәрләрнең эчтәлеген сөйли белү. Сәнгатьле уку күнегүләре |
| 66. | Матурлыкка бай ул безнең заман. И.Юзеев “Матурлыкны гына алып кит” | 21.05. | | Тормыш матурлыгы белән табигать матурлыгын бербөтен итеп карау Әсәрнең төп фикерен билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү. |
| 67. | Мин яратам сине, Татарстан! Г.Бәширов “Безнең Татарстан”. Р.Харис “Игенче җыры” | 24.05. | | Татарстан турында әдәби әсәрләр аша танышу Әсәргә анализ ясау; йөгерек, дөрес, сәнгатьле уку. |
| 68. | Казан – спорт каласы. Йомгаклау дәресе. Йолдыз “Спортчы Шүрәле”. Г.Гыйльман “Универсиада” Йомгаклау дәресе. | 28.05 | | Әсәрләр турында мөстәкыйль нәтиҗәләр ясау Әсәрнең төп фикерен билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү |

**Әдәбият**

1. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 3 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 1 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт* нәшрияты, 2013.
2. . Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 3 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 2 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2013.
3. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 3 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 3 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 20Т5Г
4. Г. М, Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: Мөстәкыйль эш дәфтәре. 3 нче сыйныф. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2013.
5. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 3 нче сыйныф: Методик кулланма. — Казан: